Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының егерме икенче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

2019 елның 8 октябре № 138

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Питрәч авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Питрәч авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 сентябрендәге 137 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары һәм Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 20 сентябрендәге 25 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. 2019 елның 8 декабренә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2020 елда 18 яшькә җиткән, 1 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, мәктәп укучыларыннан кала, аның яшәү урыны Питрәч авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, Россия Федерациясенең һәр гражданинынннан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне расларга:

- Питрәч авылында тротуарлар төзү;
- Олан Иле авылында балалар мәйданчыгы төзү һәм чишмә төзекләндерү;
- Шихазда авылы зиратына кадәр авыл эчендәге юлларны һәм юлларны төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, Питрәч авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) халыкка хәбәр итәргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИНН 1633000909